**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Нырты авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**10 ноябрь 2021 ел** **№ 39**

**«Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбия авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 19 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбия авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Яңа Чәбия авылы, Бакча урамы, 55 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчет йорты бинасы ишек алдында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбия авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Яңа Чәбия авылында урнашкан чишмәне төзекләндерү (смета документларын эшләү һәм түләү, чыгым материалларын сатып алу һәм ташу, килешү һәм техник күзәтчелек буенча эшләр өчен түләү);
- Яңа Чәбия авылы территориясен төзекләндерү (җәйге чорда территорияне чабу, өрәңге агачларын кисү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, хуҗасыз ташландык йортларны җимерү, территорияне чүп-чардан арындыру);
- Яңа Чәбия авылы зираты коймаларын буяу һәм ремонтлау (чыгым материалларын сатып алу һәм ташу, килешү һәм техник күзәтчелек буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»?

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Нырты авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Нырты авыл җирлеге башлыгы Т.А.Котдусов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ • ТР КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НЫРТЫ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ • НЫРТИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОГРН 1061675011243
ИНН 1623008592